Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXIX- 2**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 19 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2017 елның 28 декабрендәге XXV-6 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30, 45 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2017 елның 28 декабрендәге XXV-6 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәгә кушымтага ярашлы рәвештә үзгәрешләр кертергә.

2. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе башлыгына Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 18 нче номерлы районара инспекциясендә әлеге карар нигезендә Нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алуны законнар белән билгеләнгән тәртиптә үткәрүне тәэмин итәргә вәкаләт бирергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
Район Советының 2018 елның
19 февралендәге XXIX-2 номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2017 елның 28 декабрендәге XXV-6 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2017 елның 28 декабрендәге XXV-6 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.3 пунктны төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлектәге 6.1.21 пунктын өстәргә:

"6.1.21) муниципаль белем бирү оешмаларын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруда катнашу кысаларында муниципаль белем бирү оешмалары уставларын раслау, шулай ук муниципаль белем бирү оешмалары уставларына кертелә торган үзгәрешләр.".